ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон ______________ КАРАР

Шәхси яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына үзгәрешләр кертелүгә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры" дәүләт мәгълүмат системасы турында" 2010 елның 10 сентябрендәге 729 номерлы карарларына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2011 елның 23 декабрендәге 961 номерлы, "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры турында" 729 номерлы карарларны кабул итүгә бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шәхси яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) икенчесенә күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын» расларга.

2. «Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 15 августындагы 1093 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

2018-335